Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең
Рус Акташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

4декабрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 27 ноябрендәге 16 сәгать 00 минутта, 2023 елның 28 ноябрендә 16 сәгать 00 минут, 2023 елның 2 декабрендә 14 сәгать 00 минутта булган гражданнарның этаплы җыеннары нәтиҗәләре нигезендә, «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тышһәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү һәм техник күзәтү үткәрү өчен түләү?»соравы буенчагражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 2879 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 1498 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 1498«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның0«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегененҗРус Акташы авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.”Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү һәм техник күзәтү үткәрү өчен түләү?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Рус Акташы авылы, Төзүчеләр ур., 14 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Рус Акташы авыл җирлеге башлыгы С.А. Белоногов